КЕЧКЕНӘДӘН БЕЛӘСЕ

Киләсе елдан тарих дәресен 1 сыйныфтан укыта башларга мөмкиннәр

> 3

НӘСЕЛ ҖЕБЕ

Йосыповлар җиде буынга кадәр барып җитәргә, аннан ары да китәргә хыялланалар

> 3

ГАСЫРЛЫК ЮЛ

«Казан утлары» журналы 100 еллык юбилеен билгеләп үтте

> 3

ЧЫН КҮҢЕЛДӘН

Балтач эшмәкәрләре оештырган хәйрия чарасы бәйрәмгә әверелә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 60 (28833) | Чәршәмбе | 27 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ЯШӘ, ТУКАЙ ТЕЛЕ!

И туган тел!

Тукай безнең көннәр турында ни дияр иде икән? Туган тел көнендә, мәйдан тотып, ачынып, әрни-әрни шигырь сөйләр иде ме ул? Яшьтәшләренең милләт турында фикер алышуларын тыңлап горурланыр идеме икән? Бу сорауларга җавапны һәркем үзе табар кебек. Туган тел көне һәм Габдулла Тукайның тууына 136 ел тулган көн мизгелләре – безнең репортажда.

tatarstan.ru

Бергә ким

Туган тел көне, гадәттәгечә, Габдулла Тукай һәйкәленә чәчәкләр салудан башланды. Әлеге чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Республиканың Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм министрлар катнашты.

Тантаналы чараларның күпләр өчен иң көтелгәне Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында узды. Биредә Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы ияләре билгеле булды. Дәүләт бүләген Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тапшырды.

– Бөек шагыйребезнең иҗаты төрле буын һәм һөнәр кешеләрен, ата-бабаларыбызның мәңгелек идеяләрен һәм кыйммәтләрен берләштерә. Тукай – милләтебезнең рухи һәм мәдәни үсешенә юл күрсәтүче якты йолдыз. Бүген безнең алда туган телне һәм татар халкының бай мәдәни мирасын саклау, аларны киләчәк буыннарга тапшыру максаты тора. Шуңа да без яшь буын белән эшләүгә аерым игътибар бирәбез. Үсеп килүче буынны тәрбияләүдә, халкыбызның бай рухи мирасын киң җәмәгатьчелеккә тапшыруда мәдәният, әдәбият, мәгариф, фән эшлекләре мөһим роль уйный. Аларның иң зур казанышлары исә Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән билгеләп үтелә, – диде ул тантаналы чарада.

Быел Тукай премиясенә ике кеше генә лаек дип табылды. Анатолий Егоровка ул «Над Казанью луна» гобеленнар циклы һәм Татарстанның декоратив-гамәли сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән өчен тапшырылды. «Мин бөтен гомеремне сәнгатькә багышладым. Бүген мин гаять бәхетле», – диде бүләк иясе.

Ләбиб Леронга премия «Җил көймәсе», «Әкиятче малай» китаплары өчен бирелде. «Тукай һәр каләм иясенең йөрәгендә яши – минем моңа шигем юк. Гәрчә аның яшен инде күптән узсам да, иҗаттагы һәм тормыштагы маягым ул минем. Без, иҗатчылар, Тукайга һәрвакыт мөрәҗәгать итәбез. Балалар өчен язылган әсәрләремне алсак та, аларда Тукай образы, аның геройлары чагылыш таба. Алар шигырьләремә дә бәреп керә. Шул рәвешле мин Тукайга гына түгел, милләтебезгә карата да мәхәббәтемне аңлатам», – дип сөйләде ул безгә.

Быел әлеге премиягә 19 кандидат дәгъва кылган иде. Моңарчы Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, Татарстан Президенты указы нигезендә, өч кешегә бирелде. Премиянең саны бергә арткан очраклар да булды. Ә инде комиссия премиягә дәгъва кылучылар арасында лаеклылар азрак дип тапса, Дәүләт бүләге лауреатлары да кимрәк булырга тиеш.

«Без – аның бик зур фәхерле, чын бриллиант кашлары!»

Габулла Тукайның яшьләргә багышланган шигырьләренең берсендә әнә шундый сүзләр бар. Бәйрәм көнендә иҗади татар яшьләренең милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге турында фикер алышуы һич юкка түгел, димәк. Алар «Шәрык клубы»нда узган очрашуда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка үз фикерләрен, теләк-тәкъдимнәрен җиткерде.

Әйтик, медиаменеджер, продюсер Динә Гәрәева Мәдәният министрлыгы каршында Бердәм продюсерлык үзәге булдырырга тәкъдим итте. «Заманча татар эстрадасы – милләтнең йөзе. Тик, кызганыч, бүген эстрадада тәртип җитми. Бу җырчыларның репертуарында да, авторлык хокукларына кагылышлы мәсьәләләрдә дә чагыла. Безгә татар эстрадасы үсеше өчен шартлар тудыру буенча стратегик план кабул итәргә кирәк», – диде ул, Рөстәм Миңнехановка мөрәҗәгать итеп. Әлеге үзәк яшь талантларны барлау, милли репертуар мәсьәләсе һәм башка сораулар белән шөгыльләнер, әйтик, фонограммага каршы чаралар табар иде, дигән фикердә Динә Гәрәева. «Бик дөрес, мин фонограммага каршы», – диде Президент та, аны хуплап.

Ахыры 4 нче биттә >

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

2022 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясенең 2022 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген тапшыру турындагы тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:
1) Егоров Анатолий Николаевичка – Татарстан Республикасының декоратив-гамәли сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе, «Над Казанью луна» («Казан күгендә ай») гобеленнар циклы өчен;
2) Леронов Лемон Лерон улына (Ләбиб Леронга) – «Җил көймәсе», «Әкиятче малай» балалар китаплары өчен.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 25 апрель, № ПУ-301

Өч процентка кими

Премьер-министр Михаил Мишустин Финанс, Икътисади үсеш, Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыкларына ташламалы ипотека ставкасын кичекмәстән 12дән 9 процентка калдыру өчен барлык документларны әзерләргә кушкан. Үзгәрешне ничек тә тизрәк кертергә ниятлиләр. Бу хакта Хөкүмәтнең матбугат хезмәте хәбәр итә. Моңа кадәр Президент Владимир Путин ташламалы ипотеканы 9 процентка калдыру тәкъдиме белән чыккан иде. Ул хәзер вазгыятьнең уңай булуын һәм бу адымны ясарга мөмкинлек бирүен аңлатты.

Исегезгә төшерәбез: ташламалы ипотека март азагында 7дән 12 процентка кадәр күтәрелде. Шул ук вакытта гаилә ипотекасы ставкасы (балалы гаиләләр өчен – 6%), авыл ипотекасы (3%) һәм Ерак Көнчыгыш ипотекасы (2%) үзгәрешсез калды.

Җиңү көне тасмасы

Бүген Казанда «Георгий тасмасы» халыкара акциясе башланды. Җиңү көне символына әйләнгән тасмаларны шәһәр урамнарында 10 майга кадәр «Патриот» спорт-ватанпәрвәрлек үзәге волонтерлары өләшәчәк. Яшьләр министрлыгы хәбәренә караганда, башкалада тасмалар өләшү буенча 15кә якын пункт эшләячәк. Истәлек һәм хәрби дан символы Камал театры янындагы мәйданчыкта, Җиңү, Меңьеллык парклары, Ирек мәйданы, Петербург һәм Бауман урамнары, шәһәрнең сәүдә үзәкләре, метро станцияләрендә таратыла. Быел үзәк барлыгы 200 мең тасма әзерләп куйган.

Илебездә «Георгий тасмасы» акциясе беренче тапкыр 2005 елда узды. Шуннан бирле ул һәр ел саен үткәрелеп килә. Җиңү көне алдыннан Россиядә, шулай ук якын, чит илләрдә яшәүче миллионнарча кеше үзләренең күкрәгенә, шәхси транспортына буй-буй тасманы беркетә.

«Татар-информ»

Каты чирләүчеләр арткан

Татарстанда коронавирус йоктыру сәбәпле хастаханәгә эләгүчеләр саны өч тапкыр арткан. Коронавируска каршы көрәш буенча оператив штаб хәбәр иткәнчә, соңгы тәүлектә республикада инфекция ияртүнең яңа 226 очрагы (узган тәүлектә – 228) теркәлгән. 78 сырхауны (алдагы көнне нибары 26) хастаханәгә салырга туры килгән. Гомумән алганда, пандемия башланганнан бирле Татарстанда коронавирус йоктыруның 143747 очрагы расланган. 137635 кеше савыккан, шул исәптән узган тәүлектә 230 кеше терелеп аякка баскан. Шушы чорда барлыгы 1970 сырхау вафат булган, өчесе – соңгы тәүлектә.

Россия буенча мәгълүматларга килгәндә, узган тәүлектә барлыгы 7107 кеше чир йоктырган. Алдагы көнне 7651 кешенең чирләп китүе турында хәбәр ителгән иде. Ил күләмендә бер тәүлеккә 176 кеше вафат булган (алдагы көнне – 159). Хастаханәгә салынучылар саны ил буенча да бер көн эчендә өч тапкыр диярлек артып, 1112 очрактан 3161гә җиткән.

Социаль яклау

Хәлеңә карап, акча түлиләр

1 майдан 8–17 яшьлек бала үстерүче әти-әниләр яңа түләү ала башлаячак. Әлеге пособие гаиләнең кереме җан башына яшәү минимумыннан кимрәк булган очракта түләнә. Аны йә әти, йә әни кеше рәсмиләштерә ала. Ул Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәсе аша түләнәчәк.

Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова моңа охшаш түләүләрнең инде булганлыгын искә төшерде. Хәтерләсәгез, 2020 елда пандемия вакытында бер гариза биреп кенә дә, балаларга ике мәртәбә 10 мең сум пособие алган идек. Ул чакта гаиләнең кереме исәпләнмәде. Ә менә быелгы түләүләр бары тик мохтаҗ саналган гаиләләргә генә биреләчәк. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган очрашуда әйттеләр.

Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин эшлекле сәфәрдә булу сәбәпле, видеоэлемтә аша гына элемтәгә чыкты. Аның сүзләренчә, әлеге акчаны алырга өмет итүче гаиләләр күп булачак. Якынча 400 мең кеше булыр дип көтелә, ди ул. Ә менә фаразлар буенча, әлеге түләү 79 мең балага эләгер дип көтелә.

– Әлеге түләүне биргәндә гаиләнең матди хәле төрле яктан тикшерелә. Әгәр гаиләнең уртача айлык кереме республикада җан башына билгеләнгән яшәү минимумыннан – 10756 сумнан ким була икән, әлеге пособие бирелә, – ди Эдуард Вафин. – Бу акчаны алучы әти-әнинең дә, баланың да Россия гражданы булуы шарт. Гаиләдә 8–17 яшьләр арасында берничә бала бар икән, мохтаҗ дип табылган очракта, аларның һәрберсенә бу пособие ай саен түләнәчәк. Бер гариза белән бу түләүне бер ел буе алып була. Аннан соң документларны яңадан китерергә кирәк булачак.

Татарстанда сабыйларын ялгызы гына тәрбияләүче әниләргә 8–17 яшьлек балалар өчен пособие бирелә иде инде. Аларга ике пособиенең берсен генә түләячәкләр. Әмма яңа түләү өчен ялгыз әнинең яңадан гариза бирүе кирәк. Әгәр ул гариза бирми икән, элеккеге түләве кала. Мөрәҗәгать иткән очракта, Эдуард Вафин әйтүенчә, түләүнең кайсы күбрәк чыга, шунысын бирәләр.

Яңа пособиене алу өчен гаризаны интернет аркылы, Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси бит аша да тапшырып була. Әгәр инде кешеләрнең мондый мөмкинлеге юк икән, Күпфункцияле үзәкләрнең офисларында тапшырып була. Бу хакта Татарстанның Күпфункцияле үзәк дәүләт оешмасы директоры Ленара Мозаффарова хәбәр итте.

– Безнең үзәкләр 1 майдан 10 майга кадәр ял көннәрсез эшләячәк. Апрельнең соңгы эш көнендә 8 яшьтән алып 17 яшькә кадәрге балалар өчен яңа түләүләргә гаризалар кабул ителмәячәк. Документларны бары тик май башыннан гына тапшырып була. Бер дә борчылмагыз. Балагызга 1 май көнне 17 яшь тула икән, аңа да бу түләү биреләчәк. Майның кайсы көнендә килсәгез дә ярый, – ди ул. – Әгәр ата-аналар Дәүләт хезмәтләре порталы аша гариза бирә алмасалар, күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итә ала. Безнең хезмәткәрләр порталда шәхси бит ачарга да булыша. Аннары инде, әгәр тели икән, әти-әниләр гаризаны өеннән дә бирә ала. Әмма бер теләк бар: безнең үзәкләргә документларның төп нөсхәләре белән килсәгез иде. Без сез тутырган гаризага документларыгызның күчермәсен дә беркетеп куябыз.

Бәйрәм көннәрендә «Минем документлар» офисларының эш режимы үзгәрә. 1, 2, 3, 7, 8, 9 һәм 10 май көннәрендә офислар 10.00 – 14.00 сәгатьләрдә кизү тору режимында эшләячәк. Бу көннәрдә кабул итү бары тик 8–17 яшьлек балалар өчен түләү буенча гына булачак. 4, 5, 6 майда күпфункцияле үзәкләрнең офислары гадәти режимда эшләячәк.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Татьяна МОСКАЛЬКОВА, Россиянең Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле:

Бөтен ил буенча бакча, мәктәп һәм колледжларда куркынычсызлык чараларын көчәйтергә кирәк. Бу бик тә җаваплы бурыч Росгвардиянең ведомстводан тыш сак хезмәткәрләре өстендә булырга, алар тәүлек буе сакта торырга тиеш.

(Телеграм-каналда Ульян өлкәсендәге балалар бакчасында өч кешенең үлеменә китергән фаҗигадән соң әйткән фикере)

РОССИЯДӘ – МАШИНА САТУ

2022 елның 3 аенда Россиядә 277332 яңа җиңел автомобиль сатылган. «Автостат» агентлыгы мәгълүматларына караганда, бу узган елның шул чоры белән чагыштырганда 28,4 процентка азрак.

ИҢ КҮП САТЫЛГАН МАШИНА МОДЕЛЬЛӘРЕ

	Исеме	Сатылган машина саны	Узган елгыдан аермасы (%)
1	Kia Rio	17017	– 30,9%
2	Лада Vesta	16281	– 31,8%
3	Лада Granta	15179	– 49,7%
4	Hyundai Solaris	13802	– 7,6%
5	Hyundai Creta	10054	– 48,0%
6	Лада Нива	9307	– 29,5%
7	Renault Duster	8526	+ 15,8%

Махсус режим башланды

Татарстанда янгынга каршы махсус режим башланды. Янгын күзәтчелеге буенча баш дәүләт инспекторы урынбасары Максим Трущин әйтүенчә, елның-елында нәкъ менә апрель аенда ут чыгу очраклары арта. Асылда бу, куркынычсызлык таләпләрен үтәмәү сәбәпле, корыган үләннең янып китүенә бәйле. Трущин сүзләренә караганда, узган елда янгын сагы хезмәткәрләренә кайвакыт бер көн эчендә йөзәр тапкыр янгын сүндерергә туры килгән.

Махсус режим чорында МЧС, янгын сагы һәм полиция хезмәткәрләре уртак рейдлар уздыра. Корыган үлән, чүп-чар яндыручыларны штраф көтә. Аның күләме бу чорда ике тапкыр зуррак булачак.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АЕК АКЫЛ ӨСТЕН ЧЫГАРМЫ?

Яңа атна дөньякүләм вакыйгаларның тагын да кайнарлануы белән старт алды. Кызганыч, иң киеренке вакыйгалар Россиянең көнбатыш чикләрендә куера. Финляндия һәм Швеция, Мәскәүнең бик кисәтүенә карамастан, НАТОга таба борылдылар. Моңарчы гел нейтралитет саклаган һәм Россия белән актив хезмәттәшлек иткән бу илләрнең Төньяк Атлантик блокка кушылуы – Мәскәү өчен бик зур минус ул. Финляндия чигеннән Петербургка кул сузымы гына, Мәскәүгә дә ерак түгел. Англия һәм башка кайбер державалар бу дәүләтләргә, НАТОга кушылганчы ук, югары технологик корал белән үз хәрбиләрен китерәчәкләр дигән хәбәрләр дә бар.

Дүшәмбе кичендә Молдовада хәл киеренкеләнде. Россия контролендәге Приднестровьеда дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы бинасына граната аттылар. «Путин в Telegram» каналы сишәмбе иртәсендә Приднестровьеның Парканы авылында шартлаулар ишетелүен хәбәр итте. Румыниянең Молдовадагы вазгыятькә Төркия белән бергәләп йогынты ясарга җыенуы турында имеш-мимешләр таратылды. Россиянең Тышкы эшләр министрлыгы бу уңайдан тынычландыргыч белдерү таратты.

Бер үк вакытта тышкы эшләр министры Сергей Лавров берничә мөһим игълан ясады. Өченче Бөтендөнья сугышы башлану ихтималы турында: «Куркыныч җитди һәм реаль», – диде, атом-төш коралын куллану куркынычының зур булуын әйтте. Әмма Мәскәү дипломатиясе бу юлы андый дәһшәтне булдырмый калу ягын куәтләде, атом күсәген селтәмәде. Министрның: «Украинага корал китереп, НАТО Россия белән прокси сугышка кушыла», – дигән сүзләре сагайта, әлбәттә. Башка илнең мөмкинлекләреннән файдаланып, читтә сугыш оештыру дигән сүз бу. Чынлап та, соңгы көннәрдә Украинага Көнбатыштан авыр хәрби техника һәм яңа технологик кораллар күпләп китерелә. «Путин в Telegram» каналы Киевка бирелгән яңа Америка ракетасы AGR-20нең Россия радиоэлектрон көрәш системаларын (РЭБ) әйләнеп уза торган итеп эшләнүе турында яза. Phoenix Ghost дип аталган яшерен корал хакында әлегә Россиядә мәгълүмат та юк икән. Аны яңа камикадзе-дрон булырга тиеш дип уйлыйлар. Элек Украинага китерелгән дроннарга караганда ераккарак оча алуы белән аерылып тора дип санала. Әлегә Брянск өлкәсендәге нефть базасында янгын нилектән чыгуын да аңлатып бетерә алмыйлар. «Российская газета»ның Telegram каналы беспилотниклар һөҗүме булырга мөмкин дигән фараз гына белдерә. Мәйданга күп санда беспилотниклар һәм барражирлаучы дроннарның чыгуы конфликт мәйданының кан коелышлы һәм югалтулы булачагын вәгъдә итә. Польшаның Жешув аэродромына исә корал төягән хәрби-транспорт очкычлары АКШтан да, Бөекбританиядән дә күпләп төшеп утыра.

Көнбатыш илләре актив рәвештә Россия дипломатларын куып чыгаруны да дәвам иттерә. «Российская газета»ның Telegram каналы, махсус операция башланганнан соң, 28 илдән 400ләп дипломатның кайтарып җибәрелүен хәбәр итә. Россиянең АКШтагы Хьюстон каласында урнашкан генераль консуллыгына янаулар килә, дип тә яза. Дипломатларның андый масштаблы сөрелүен тарих хәтерли микән, бу юллар авторына мәгълүм түгел. Менә бу хәлләр барысы да без яшәгән илнең зур сугыш мәйданына әверелү ихтималлыгына ишарә итәләр. Әмма өметләник: аек акыл ахыр чиктә өстен чыгар. Бу юллар язылган сишәмбе көнне Әрдоган яңадан Путин белән сөйләшә. Төрек лидерының элемтәсе гадәттә нәтиҗәле була. Лавров та Украина белән конфликтның килешү белән тәмамланачагын анонслады.

Россиядә

ӨМЕТЛӘНӘБЕЗ ДӘ, ХӘВЕФЛӘНӘБЕЗ ДӘ

Илнең эчке тормышында өметле хәбәрләр хәвефлеләре белән үзара чиратлаша. Дүшәмбе чын мәгънәсендә «утлы» көн булды. Брянск өлкәсендәге стратегик нефть базасыннан тыш тагын берничә урында зур янгыннар чыкты. Мәскәүдә «Ефәк юлы» («Шелковый путь») сәүдә үзәгенә ут капты, Себердә традицион урман янгыннары көчәя... Тверьдәге оборона фәнни-тикшеренү институтындагы янгын корбаннары унсигезгә җитте. Бу әле соңгы сан түгел, диләр, чөнки авыр хәлдәгеләр бар.

Транспорт министрлыгы, авиакомпанияләр пассажирларга файдаланылмаган 1 миллион билет өчен акчаны кайтарып бирә, дип сөендерә. «Аэрофлот» төркеме март аенда пассажир ташуны 20,4 процентка киметкән икән.

Путин: «Россия икътисадының тотрыклы эшләве өчен бөтен мөмкинлекләре дә бар», – дип шатландыра. Бик нык күтәрелгән бәяләр кайчак бераз гына төшәләр дә төшүен, әмма 24 февральгә кадәрге бәяләргә без беркайчан да кире кайтмабыз инде, мөгаен. Бәяләр бизнесның, комсызланып, сәхнә артында үзара килешүе сәбәпле күтәрелде нигездә. Андый килешүләрне картель килешүләре дип атыйлар. Владимир Владимирович та моны яхшы төшенә. Аның: «Бизнеска ирек тәэмин итәргә кирәк, әмма сәхнә артындагы картель килешүләренә реакция ясамый булмый», – дигән сүзләре шуңа ишарә. Сүзләр прокурорларга әйтелде, димәк, бәяләрне көч структуралары контрольгә алырга тиеш булып чыга.

Росатом белән «Норникель» Мурманск өлкәсендәге литий ятмаларын эшкәртү өчен уртак предприятие ачарга мөмкиннәр, дигән хәбәр дә куанычлы. Литийдан башка технологик үсеш мөмкин түгел, ә аны Россиягә сатучы чит ил партнерлары безгә китерүдән баш тарталар. Хәер, мөмкин дигән сүз эшләнде дигәнне аңлатмый әле, күп акча һәм җиһазлар таләп ителә проектны тормышка ашыру өчен.

Эшләү өчен мөмкинлекләр бар, вәләкин санкцияләр үз эшен эшли инде барыбер. «Урал» мотоциклларын җитештерүче Казахстанга күчә, ди әнә «Российская газета» каналы. Күчүнең сәбәбе: комплектлаучы детальләрнең җитмәве һәм чит илләрнең Россиядән техника импортлаудан баш тартуы. Икенче сәбәп аеруча зур әһәмияткә ия, чөнки моңарчы «Урал»ларны россиялеләр түгел, ә чит илләр, аеруча көнбатышлылар күбрәк сатып алган икән.

Илгә нефть һәм газ акчасы күп керә, әмма Эльвира Нәбиуллина: «Россия, кирәк булганда, алтын-валюта резервларының бер өлешен импортка түләү өчен тота ала», – дип белдерде. Менә шундый контраст яңалыклар инде.

ЭШ ХЫЯЛДАН БАШЛАНА

ТАТАРСТАНДА ИННОВАЦИОН ПРОЕКТЛАРНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУДА ЯРДӘМ ИТӘЧӘКЛӘР

Уй – хыялга, хыял проектка китерә. Татарстанда фәнни-технологик һәм инновацион үсешне арттырмакчылар һәм технологик эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү юнәлешендә эшне көчәйтмәкчеләр. Ничек икәнен журналистларга сөйләделәр.

worldskills.ru

Татарстанда инновацион проектларга ярдәм итү программалары белән республиканың инвестиция-венчур фонды, «Идея» технопаркы, Казан федераль университеты һәм Иннополис университеты стартап-студияләре вәкилләре таныштырды.

– Хәзерге шартларда яңа идеяләргә һәм технологик эшмәкәрлеккә ярдәм итү аеруча мөһим, – диде Татарстанның инвестиция-венчур фонды җитәкчесе Айнур Әйделдинов. – Безнең фонд та шуларга ярдәм итүгә йөз тота. Без башлангычта ук проектларны ачыклау һәм сайлап алу, аларга таяныч булу белән шөгыльләнәбез, бездә эшмәкәрлек эшчәнлеге нигезләренә өйрәтү буенча система төзелгән.

Әлеге бурычларны фонд инде күпләр өчен билгеле булган чаралар кысасында тормышка ашыра. «Болар – Татарстан өчен 50 иң яхшы инновацион идея», «Идея –1000», Россия венчур форумы, инновацион проектлар акселерациясе программалары һәм башкалар. Алар үз нәтиҗәсен бирә. Татарстанда эшмәкәрләрнең уңышлы рәвештә тормышка ашырылган технологик проект мисаллары бар инде. Алар – мин санап үткән юллардан узучылар. Мәсәлән, «Ирбистех» компаниясе. Аларның идеядән башлап, тулы куәткә эшләүче бизнеска кадәр юлы биш елга сузылды. Бу компания криотехнологияләр белән шөгыльләнә. Хәзерге вакытта төрле тармакларда коры боз җитештерү һәм куллану ихтыяҗы зур. Проект башлангыч этапларда төрле программалардан файдаланып матди ярдәм алды. Тагын бер үрнәк – «Юрли» компаниясе. Алар скоринг (компанияләрнең кредит түләү сәләтен бәяләү системасы. – **Авт.**) өчен интеллектуаль программа уйлап тапты. «Ондер лаб» дигән компания энергетика тармагы өчен цифрлы ярдәмче булып тора. Хәзер яңа проектлар өчен яңа программаларны гамәлгә кертә башлаячакбыз», – диде Айнур Әйделдинов.

Асылда хәзерге вакытта «Университет технологик эшмәкәрлек платформасы» федераль проектын тормышка ашыруга йөз тоталар. Аның кысасында берничә бәйге игълан итү каралган. Исеменнән аңлашыла инде: проектның максаты – яшьләрне, студентларны эшмәкәрлек өлкәсенә җәлеп итү, аларның башында йөргән хыялларын проект итеп, тормышка ашыруда булышу.

Әлеге проект матур нәтиҗәләр бирер дип өметләнәләр. Әйтик, 2024 елга акселерация (билгеле бер методикалар кулланып, бизнес үсешенә ирешү. – **Авт.**) программаларын узган студентлар санын 435 меңгә кадәр җиткерү, яңа идеяләргә инвесторларның шәхси акчасын җәлеп итүне арттыру турында хыялланалар. 2030 елга исә университет эскәмиясеннән үк башланган 30 меңләп яңа проект (стартап) барлыкка киләсенә өметләнәләр. Сүз уңаеннан, 2020 елда андыйларның саны 455 кенә булган. Үсәргә җирлек бар, кыскасы.

Бәрәңге акча китерер

Бакчачылык

Быел яшелчәчелек белән шөгыльләнүче шәхси хуҗалыкларга, фермерларга һәм кооперативларга зур игътибар күрсәтеләчәк. Орлыклык суган, бәрәңге белән тәэмин итү, субсидияләр бирү күздә тотыла. Әлеге яңалыкларны журналистларга Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ришат Хәбипов җиткерде.

– Бакчачыларга зур игътибар бирелә, чөнки без барыбыз да ризык белән тәэмин итү ширкәтләр кулында булган чорларны хәтерлибез. Билгеле бер вакытта халыкның күпчелеге һәр нәрсәне кибеттән генә сатып алырга ияләшеп китте. Ләкин узган елгы корылык нәтиҗәсендә, яшелчәләр, бәрәңге кытлыгы барлыкка килде. Нәтиҗәдә бәяләр күтәрелде. Хәтта кишернең бананнан кыйммәтрәк йөргән вакыты булды, – диде министр урынбасары.

Аның фикеренчә, быел халык яшелчә, бәрәңгене күбрәк үстерер. Моның өчен барлык мөмкинлекләр дә бар. Алай гына да түгел, яшелчәчелек белән шөгыльләнүчеләргә субсидияләр дә бирәчәкләр. Шулай итеп, бәрәңге игү мәйданнарын арттырган очракта, бер гектарга 20 мең сум күләмендә субсидия биреләчәк.

– Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре генә түгел, бакчалары булган халык та быел үзләре өчен дә, туганнары өчен дә күпләп бәрәңге утыртыр. Артып калганнарын ярминкәләрдә сатарга мөмкинлек булыр, – диде ул.

Кулланучылар кооперативларына республика орлыклык суган һәм бәрәңге дә биргән. Көзен алар артканын кире кайтарачак.

– Бәрәңгеләрне кабул итеп алганда билгеле бер таләпләр куела. «Гала» сорты аларга күбрәк туры килә, шуңа күрә без әлеге сорт белән эшлибез. Көзен халык үзеннән артканны тапшырып, үз участогында акча да эшли алачак дигән сүз, – ди Ришат Хәбипов.

Моннан тыш, быелдан башлап, федераль үзәк үзмәшгуль булып теркәлеп, яшелчәчелек белән шөгыльләнүче шәхси хуҗалыкларга субсидия бирәчәк.

– Ул ике юнәлеш буенча тапшырыла. Беренчесе – турыдан-туры шәхси хуҗалыклар, икенчесе – кооперативлар аша. Бу агроконтракт дип атала. Фермер шәхси хуҗалыкларга бушлай орлыклык бәрәңге бирә. Ә без әлеге чыгымнарны каплаячакбыз. Әгәр кооператив үзе симәнә таратса, шулай ук федераль проект хисабына субсидияләнә. Бу эшләр өчен 200 млн сум акча бирелә, – дип аңлатты җитәкче.

Бүген республиканың 23 районында 950 бакчачылык ширкәте бар. Аларда 336 бакча участогы теркәлгән. Күпчелеге Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләре янында урнашкан.

Ришат Хәбипов әйтүенчә, бакчачылар тыныч күңел белән эшләсен өчен, республикада 2017 елдан бирле тышкы объектларны рәткә китерү буенча программа эшләп килә. Бу эшләр өчен барлыгы 3 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Быел ярдәм күләме 550 млн сумны тәшкил итә. Әлеге акчалар юл челтәрләрен төзекләндерү, электр линияләрен рәтләү, су мәсьәләләрен хәл итү һәм чүплек савытларын карап тотуга каралган. Биш ел эчендә шактый гына эшләнгән.

– Тапшырылган гаризалар буенча әлеге объектларны карап чыгалар, шуннан соң без җаваплы министрлыклар һәм бакчачылык союзы белән бергә өстенлекле ширкәтләрне сайлап алабыз. 2022 ел өчен мондый эшләр күздән бирле алып барылды, – диде Ришат Хәбипов.

Татарстан бакчачылар союзы башлыгы Владимир Дейнекин хәбәр итүенчә, 30 апрельдә Восстание урамының 30 нчы йорты янында бакчачылар өчен яңа ашламалар, үсентеләр, орлыклар тәкъдим ителәчәк һәм ветераннар, авырулар өчен бүләкләр таратылачак.

– Бакчачыларның безгә ышануы мөһим. Без яңа технологияләр ярдәмендә эшләрнең нәтиҗәлелеген күрсәтергә телибез, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

РОССИЯ ПАРЛАМЕНТАРИЗМЫ КӨНЕ БЕЛӘН

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. МӨХӘММӘТШИНның Россия парламентаризмы көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле коллегалар – вәкиллекле хакимият органнары депутатлары! Кадерле татарстанлылар! Сезне чын күңелдән Россия парламентаризмы көне белән котлыйм.

Парламент, хакимиятләр бүленеше принцибына нигезләнгән дәүләт һәм җәмгыять хезмәттәшлегенең Конституциядә беркетелгән системасы буларак, бүгенге җәмгыять үсешенең мөһим факторы булып тора. Демократик дәүләтләрдә бөтен әһәмиятле карарлар парламент – закон чыгару һәм вәкиллекле хакимият органы тарафыннан кабул ителә. Федераль Собраниенең Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмәләр кабул ителгәннән соң арткан роле шушы тенденцияне чагылдыра. Күпмилләтле Ватаныбызга моңарчы күрелмәгән финанс, мәгълүмати һәм санкция басымы шартларында бу алдан күрелгән һәм акланган адым булды. Бүген барлык дәрәҗәдәге депутатларга иҗтимагый-сәяси һәм икътисади вазгыять өчен уртак җаваплылык йөкләнә һәм алар тарафыннан көн кадагындагы мәсьәләләрне үз вакытында тиз арада хәл итү алымнары эшләнә.

Татарстан Республикасы, халык хакимияте принципларына таянып, демократия юлыннан ныклы адымнар белән бара, тотрыклылыкны һәм һәрьяклап үсешне саклау өчен барысын да эшли. Парламентарийларыбыз алдында республика хокук базасын алга таба камилләштерү, Россия Федерациясенең яңартылган Төп Законы нигезләмәләренә таянып законнарны төзәтү, гражданнар мөрәҗәгатьләре һәм сайлаучылар наказлары белән системалы эшләү кебек мөһим бурычлар тора... Безнең стратегик максат – икътисадның инновацион үсеше, яхшы тормыш дәрәҗәсен тәэмин итү, шәхеснең ирекле үсеше өчен уңайлы мохит булдыру, милләтара һәм динара татулыкны ныгыту. Ачыклык, үткәннәргә ихтирам һәм республика халкы, граждан җәмгыяте институтлары, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары белән конструктив хезмәттәшлек, һәрвакыт нәтиҗәле эшләргә омтылыш – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының какшамас төп принциплары.

Шушы истәлекле көндә бөтен татарстанлыларга тынычлык, иминлек, сәламәтлек һәм бәхет, ә халык вәкилләренә карарлар кабул итүдә зирәклек һәм парламент эшчәнлегендә туган республикабыз, илебез хакына уңышлар телим!

Мәскәүдән котлау килде

Россия парламентаризмы көне уңаеннан Федераль Җыенның Федерация Советы Рәисе Валентина Матвиенко Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм парламент депутатлары исеменә котлау юллаган.

«Төбәкләр парламентлары федерация субъектларында яшәүчеләрнең турыдан-туры вәкиллеге институты булып тора, – диелгән котлауда. – Закон чыгаручыларның эшчәнлеге гомер-гомергә илне үстерүгә һәм халыкның тормышын яхшыртуга юнәлдерелә. Нәкъ менә шуңа күрә парламентчылар үз төбәкләрендәге проблемаларны һәрвакыт бик яхшы белә, сайлаучылар белән даими элемтәдә торып, кешеләрнең ихтыяҗларын ничек тә тулырак канәгатьләндерү йөзеннән тиешле карарлар кабул итә. Моңарчы күрелмәгән кыенлыклар шартларында төбәкләр бөтен ил тирәсендә бер йодрыкка берләшкән бер мәлдә, закон чыгаручыларның үз бурычларын максималь дәрәҗәдә төгәл һәм җаваплы үтәячәкләренә ышанам».

Валентина Матвиенко парламентчыларга халык, төбәкләр һәм Россия файдасына яңа уңышлар теләгән.

ХӘЛЕҢӘ КАРАП, АКЧА ТҮЛИЛӘР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Пособие алу шартлары

✓ Пособиене алу өчен – гариза бирүченең паспорты, СНИЛС, язылышу яки аерылышу таныклыгы, ир яки хатын үлгән очракта – үлү турында таныклыгы, эш урыныннан белешмә, эш бирүченең ИНН таныклыгы, алимент суммасы турында белешмә, эшкә яраксыз кешене тәрбияләү турында белешмә, банк исәп-хисаплары яки МИР картасы реквизитлары, балаларның паспорты, туу турында таныклыгы, СНИЛС кирәк булачак.

✓ Яңа түләүнең суммасы 10433 сумнан (республикада балалар өчен яшәү минимумы суммасы) чыгып исәпләнә. Мохтаҗ гаиләләргә аның яртысы – 5216 сум 50 тиен бирелә. Әмма аны исәпләгәндә, гаиләнең җан башына тигән уртача кереме яшәү минимумының яртысыннан ким икән, бу очракта акча 75 процент күләмендә түләнә. Ягъни 7824 сум 75 тиен тәшкил итә. Әгәр гаиләнең җан башына уртача кереме яшәү минимумының 75 процентыннан ким икән, бу очракта 100 процент, ягъни 10433 сум түләнә.

✓ Бу түләүне алу өчен айлык керем ничек санала? Гаилә гариза биргән көннән 4 айга артка чигенергә кирәк. Аннары шушы айга кадәрле бер еллык керемне исәплисең. Шуны 12 айга бүләсе. Килеп чыккан сумманы тагын гаиләдәге кешеләр санына бүләргә кирәк. Ир һәм хатынның икесенең дә кереме исәпләнә. Әгәр аларның берсе беркайда да эшләми икән, бу очракта түләү бирелмичә дә калырга мөмкин. Әгәр әти яки әнинең берсе эшсез калган, Мәшгульлек үзәгенә баскан икән, бу очракта аның элеккеге керемнәре исәпләнми һәм бу очракта түләүне алты айга гына билгелиләр. Аннан соң яңадан гариза язарга һәм документлар тапшырырга туры киләчәк.

✓ Әлеге түләүне билгеләгәндә өйдә бала тәрбияләүче күпбалалы әнинең, берүзе генә бала үстерүче әнинең яки әтинең, 3 яшькәчә бала белән декрет ялындагы кешенең, 80 яшьтән өлкәнрәкләрне караучы, 23 яшькәчә көндезге бүлектә укучы, армиядән кайтканына өч ай булмаган, 3 айдан артык хастаханәдә дәвалану үтүче, эшсез, төрмәдә һәм аннан чыкканына 3 ай булмаган кешеләрнең керемнәре исәпләнми.

✓ Мохтаҗлыкны билгеләгәндә гаиләдәге милекне дә, машина булуын да, җир мәйданын да исәплиләр. Әгәр кешенең шәһәрдә теркәлгән урында 0,25 гектар, авылда яшәүчеләрнең 1 гектардан артык җире бар икән, әлеге түләүгә өметләнә алмый. Шулай ук кешенең йә 2 машинасы, йә 2 мотоциклы, йә 250 ат көчле машинасы булса, бу акча бирелми. Шулай ук гаилә кереме яшәү минимумыннан артып китүчеләргә, гариза хаталы язылса, дөресләр өчен документларны

Илдар Мөхәммәтҗанов

биш көн эчендә алып килмәүчеләргә, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүчеләргә, 17 яше тулганнарга, уллыкка алган баланы кире тапшырганда, баланы башка кешегә тәрбиягә биргәндә, баланы дәүләт оешмасына урнаштырганда, түләүне алучы эшкә яраксыз дип табылганда, пособие билгеләнгән бала яки аны алучы кеше үлгән очракта, түләүне алучы эзләүдә яки сак астында булса, бу акча бирелмәскә сәбәп булып торачак.

✓ Бу түләү гариза биргәннән соң ун көн эчендә билгеләнә. Тиешле документларны тапшырып бетермәгән очракта, билгеләү 1 айга да сузылырга мөмкин.

✓ Гаризаны Дәүләт хезмәтләре бердәм порталы һәм Күпфункцияле үзәкләр аша тапшырып була.

✓ Акчаны МИР картасына күчертергә яки почта аша алырга мөмкин.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТАРИХЫН БАРЛАГАННЫҢ КИЛӘЧӘГЕ БАР

«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ БЕР ГАСЫРЛЫК ЮБИЛЕЕН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ

Тантана 25 апрельдә Галиәсгар Камал исемендәге академия театры бинасында узды. Артистларыбыз башкаруында әдәби әсәрләр, спектакльләрдән өзекләр, җыр-моң, иҗат әһелләренең истәлекләре, фикерләре аша тарих барланды, киләчәк күзалланды, хәтер-хатирә бер сулышта күңелгә ятышлы үтте: уйландырды да, дулкынландырды да, урыны-урыны белән елмайтты да.

Иҗади, бердәм коллектив тел, милләт сагында.

– «Казан утлары» – тел, милләт сагында торучы, нинди генә авыр елларда да кыйбласын югалтмаган, халыклар арасында дуслык-туганлык, әдәби мөнәсәбәтләр урнаштыруга әдәби әсәрләр аша саллы өлеш керткән журнал ул, – дип билгеләп үтте Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов. – Алга таба да көчле язучылар кирәк, алар язганнарны яратып укучылар кирәк. Буыннар чылбыры һич кенә дә өзелергә тиеш түгел.

Ул Рөстәм Галиуллин җитәкчелегендәге иҗат коллективына Татарстан Президентының һәм Татарстан Дәүләт Советының Рәхмәт хатларын тапшырды.

Юл башы. Йөзек кашы

Хәзерге «Казан утлары» – XX башында нәшер ителгән «Әл-гасрел җәдит», «Шура», «Аң» журналларының лаеклы дәвамчысы. Журналның юл башы 1922 елдан «Безнең юл» басмасы нәшер ителә башлаудан исәпләнә. Берничә тапкыр исемен алыштыра. Хәзерге буынга ул «Совет әдәбияты», «Казан утлары» исемнәре белән мәгълүм. Галимнәребез билгеләп үткәнчә, әдәби «калын журнал» (бу – халык күңеленә кергән төшенчә) милләттәшләребезнең иҗади фикерләвен, милли үзаңын ныгыткан, рухи маяк хезмәтен үтәгән. Милләтебезнең якты көзгесе, йөзек кашы, дөньяга сибелеп яшәүче кан кардәшләребезгә нур өләшүче. Йөзьеллык уңаеннан оештырылган әдәби-музыкаль кичә дәвамында да әлеге фикер үтемле яңгырады. Моннан нәкъ йөз ел элек «Безнең юл» журналының беренче санында Зәйнәп Бәшированың «Безнең юл» дип исемләнгән шигыре дөнья күрә һәм ул, әйтерсең лә басманың озын гомерле, катлаулы һәм гыйбрәтле, шанлы-шөһрәтле булачагын алдан күрә, фаразы рас килә.

Әнә шунда таулар арасыннан
Боргаланып күренә безнең юл.
Киткән аның очы әллә кая,
Шактый ерак, байтак, озын юл...

Журналның тарихы зур, мирасы бай, рухи йөзе саллы, республикабызның медиа кырында тотрыклы урыны, даими укучысы, көтеп ала торган дуслары бар. Шунысы да игътибарга лаек: каләм әһелләренең иҗатына дәрт өстәү максатыннан күп кенә әдәби бәйгеләр дә үткәрелә, дәүләт гранты мөмкинлекләреннән дә нәтиҗәле файдаланыла. Кесәгә сыярлык китаплар чыгару да – юбилярларыбыз башлангычы, бу «Татмедиа» җәмгыяте булышлыгы белән эшләнә һәм укучыларда кызыксыну, яклау тапты.

Язучылар үзләре дә, яшьләр дә укысачы...

Шөкер, редакция папкалары әдәби әсәрләр белән шыплап тулган. Бу – бик куанычлы хәл. Әмма борчылу да бар: язучылар язуын яза, тик каләм әһелләре үзләре укымый, бер-берсенең әсәрләре белән дә кызыксынмый. Әсәрен редакциягә китереп бирә дә шуның белән эше төгәлләнгәнгә исәпли. Төзәтү, кыскарту, тулыландыру аларның вазыйфасы түгел, янәсе.

Әйе, тарихны барлау – үтә изге гамәл, әмма укучылар саны күзгә күренеп кимегәндә өметле киләчәк булырмы соң? Мондый борчылу матбугат чараларының берсен дә читләтеп узмый. Йөз еллык уңаеннан үткәрелгән бик күп чараларда – укучылар белән очрашуларда, матбугат конференцияләрендә, әңгәмәләрдә «Казан утлары» хезмәткәрләре төп акцентны киләчәгебезнең якты, өметле булачагына ясады. Безне өмет яшәтә.

Габделбәр РИЗВАНОВ

Татарстан Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВ:
«Бер гасыр дәвамында төрки дөньяда, бөтенроссия күләмендә иң абруйлы, иң өлкән басмаларның берсе булган, халкыбызның чын мәгънәсендә җан азыгы, тугры юлдашы һәм киңәшчесенә әверелгән, татар әдәби хәрәкәтенең әйдәп баручы рухи байрагына әйләнгән «Казан утлары»ның бүген дә Россиядәге калын әдәби журналлар арасында иң зур тиражлы булуы, мәдәни тормышыбызда мәртәбәле урын биләве аның нигез ташларының ныклыгыннан, редакция эшендә катнашкан шәхесләрнең милләтебезгә ихластан хезмәт итүеннән килә».

Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер ШӘЙМИЕВ:
«Журналның һәр санын укып барам. Романмы ул, повестьмы, шигырь, хикәяме – уңышлы әсәргә юлыксам, журнал битендә билгеләп куя торган гадәтем дә бар. Соңгы вакытта яшьләр иҗаты куандыра».

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИН:
«Әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси басма буларак, журнал бүген дә үз миссиясенә тугры. Ул – бүген дә әдәби процессның байрагы! Туган телебезне, мәдәни мирасыбызны, гореф-гадәтләребезне, әхлак кануннарын саклап калу, үстерү, татарны мәдәниятле, мәгърифәтле итү юлында авыр йөкне төпкә җигелеп тарта. Милләттәшләребезнең күңел җәүһәрләрен, рухи кыйммәтләрен барлап, халкыбызның рухын саклап тора».

ӘНИЕМ ЯРАННАРЫ

Мамадыш районының Кече Сон авылыннан Миңсылу апаның кызы Гөлсинә ел саен Сабантуйда үзе иҗат иткән «Әнием яраннары» җырын җырлый икән. Хәер, ул гынамы соң? Бөтен нәсел-нәсәпләре белән сәхнә тота алар. Юкка гына районда «Музыкаль гаилә» исемен яуламаганнар бит инде.

Әкүптән түгел Йосыповлар гаиләсе тагын бер җиңүгә лаек булды. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты оештырган «Без тарихта эзлебез» шәҗәрә фестиваленең Сабада узган зона ярышында призлы урынны алды. Аларның шәҗәрәсе күренекле татар композиторлары Яруллиннар нәселенә дә барып тоташа. Шуңа да җырлы-моңлы гаилә булуларына бер дә гаҗәпләнәсе юк.

Егерме биш ел туган җирендә укытучы булып эшләгән, хәзер Кече Сон авылы җирле үзидарәсе сәркатибе вазыйфасын алып баручы Венера ханым сүзен әнисен искә алудан башлады.

– Иии, гомерләр, кай арада үтеп китте соң бу? – дияр иде әни. – Кай арада үсеп, кай арада таралышып та беттегез, – дип тә өстәп куяр иде. Олыгайгач, шулай тиз үткән кебек тоелгандыр инде. Бик күпне күргән безнең әни. Ятимлек ачысын да татый. Әбиебез Хәмдениса тәрбиясендә үсә. Әбекәй бик дини кеше була, дин тыелган чагында да өендә җомга намазлары укыта, абыстай булып та йөри, балалары да дини тәрбия алып үсә. Әтиебез Хөснулланың да әтисе сугышта һәлак була. Шулай итеп, ике ятим кавыша да олы тормыш йөген бергәләп тарта башлый.

Гаиләдә бер-бер артлы алты бала туа. Ир белән хатын икесе дә, көнне төнгә ялгап, «таяк»ка фермада эшлиләр. Миңсылу апа сыер сава, Хөснулла абый ат җигә.

– Өч чакрым араны җәяүләп көненә дүрт тапкыр узарга туры килә аларга, – дип дәвам итә Венера ханым әнисе белән әтисе турындагы истәлекләрне. – Ул вакытта юллары да нинди бит: сазда итек батып кала, буранда билдән кар ерып йөрергә туры килә. «Әле ярый өйдә әбиегез бар иде. Бөтен эшне барлап, балаларны мәктәпкә озатып-каршы алучы булмаса, ничек үсәр иде ул алты бала!» – дип, гел яхшы сүз белән искә ала иде әни әбине.

Миңсылу апа белән Хөснулла абыйга сугыштан соңгы авыр елларда өч сыйныфтан артык укырга мөмкинлек булмый. Шуңа күрә балаларына: «Тырышып укыгыз, боттан саз ерулары бер дә рәхәт түгел», – дип, еш кабатлыйлар. Ә балалар, чыннан да, әйбәт тә укыганнар, тәртипле дә булганнар. Гап-гади авыл хатыны балаларын тәрбияләүдә оста педагог та була белгән. Җырга-моңга, спортка да мәхәббәт уяткан.

Акчаны тиенләп санаган чак булса да, бервакыт әниләре тальян гармун күтәреп кайта. Янәсе, малайларны гармун уйнарга өйрәтә. Әни кеше үзе дә кимен куймый: гармунны кычкырткалап, балаларын биетеп алырга да ара таба. Малайлар уйнарга өйрәнгәч, кызларның да гармун уйныйсы килә башлый. Әти кеше: «Кызлар эше түгел ул, әнә ашарга пешерергә өйрәнегез, юыгыз, җыештырыгыз», – дия диюен. Кызлар барыбер әтиләре өйдә юк чакта, мунчада, чоланда дисеңме, барысы да гармун уйнарга өйрәнәләр. Әтиләре ул арада колхоз умарталыгында эшли башлый, балалар анда да зур ярдәмче булалар. Алга китеп шунысын да әйтик: кызлар, кияүгә чыккач та, барган хуҗалыкларында умарта асрыйлар.

Шулай итеп, балаларның канат чыгарыр вакытлары да җитә. Иң олысы, мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлап, Казанга, пединститутның физмат бүлегенә укырга китә. Әти-әниләренең йөзенә кызыллык китермичә, калганнары да, югары уку йортларын тәмамлап, педагог булып эшлиләр. Уңган булган егет-кызлар бер-бер артлы үз төбәкләрендә тормыш коралар. Ә төпчек малай Рәүф төп нигездә кала, әтисе һөнәрен сайлап, умартачы була.

ШӘҖӘРӘ
«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

Тормыш гел шатлыктан гына тормый. Миңсылу апа бала югалту ачысын да татый. Уразбахты авылында физика укытучысы булып эшләүче олы улы Рәхимулла, районнан укытучылар җыелышыннан кайтканда, фаҗигале төстә һәлак була.

– Әни йөрәге ничек түзгәндер? – дип, күз яшьләренә ирек бирә Венера ханым. – Менә шул юлдан кайтып керер төсле, дип тәрәзәдән карап, үлгәнче абыебызны көтте ул. Калганнарыбыз, шөкер, исән-саулар, менә дигән итеп яшибез, һәрберебез 3–4 бала үстерде, оныклар сөябез.

Зур гаиләдә барысы да җырга-моңга гашыйк булгач, яшисе тагын да рәхәтрәк дип уйлый Венера ханым. Бергә җыелгач, һәркайсы үз һөнәрен күрсәтергә ашкынып тора икән. Ә һөнәрләр төрледән-төрле. Апасы Фираяның кызы Алсу Алабуга мәдәният көллиятендә белем ала, берничә төрле музыка уен коралында уйный. Гөлсинәләре шигырьләр, җырлар язып сөендерә. Аның улы Хәлил Казан мәдәният институтында укый, ул да җырлар яза. Венера үзе дә, төпчек кызлары Әлфинә дә, аларның балалары да бик матур җырлыйлар. Оныклар арасында шигырь язучы да, җырчы да, биюче дә, акробат та бар икән. Авылдагы бер концерт та алардан башка узмый, ди. Эштә дә сынатмыйлар. Бу җәһәттән Венера ханымның да яхшы хезмәте өчен бирелгән дипломнарын, Мактау кәгазьләрен санап бетерерлек түгел.

«Без тарихта эзлебез» дип исемләнгән зона фестивалендә катнашырга тәкъдим ясагач та, алар бердәм булуларын тагын бер кат бөтен республика алдында күрсәтә алдылар. Шәҗәрәгә нигезләнеп, сәхнәгә барысы бергә чыгып, нәсел-нәсәпләре турында хикәят сөйләделәр. Сөйләп кенә калмадылар, төрле һөнәрләргә ия булулары бик тә ярап куйды шунда.

Төптәнрәк уйлап карасаң, болар барысы да – гади авыл хатыны белән агаеның тәрбия җимешләре бит. Алар вафат инде, балаларыннан бары тик дога өмет итәләр. Монысы да аклана. Үзе дә соңгы көннәренә кадәр абыстай булган Миңсылу апаның дин юлындагы балалары, биш вакыт намаз укыганда, әтиәниләрен, әби-бабаларын догадан калдырмый. Сүз дә юк, бу гамәлләре аларның үзләренә дә бәхет, шатлык, бәрәкәтле тормыш китерә, дип уйларга кирәк.

Нәсел-нәсәпләрен барлауны дәвам иттерә алар. Алты буынга кадәр ачыклаганнар инде. Җиде буынга кадәр барып җитәргә, аннан ары да китәргә хыялланалар. Моның өчен архивларда утырырга исәплиләр. Венера ханым әйтүенчә, оныклар бик кызыксына икән. Ә яшьләрнең башына кергән әйбер тормышка ашмый калмый инде ул.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Яңалык

Белемнең артыгы булмас

Киләсе елдан тарих дәресен 1 сыйныфтан укыта башларга мөмкиннәр. Бу хакта Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов «Сила – в правде!» тарихи форумында әйткән иде. Министр фикеренчә, әлеге дәрес хәтерне сакларга ярдәм итәчәк. Әти-әниләр инде, яңа дәрес өстәмә мәшәкать булмасмы, дип борчыла ук башлады. Чынлыкта ничек булачак?

Хәзерге вакытта мәктәпләрдә тарих дәресләре 5 нче сыйныфтан укытыла. Сергей Кравцов соңрак әлеге яңалыкка: «1 нче сыйныфта балаларга аерым дәрес кертергә җыенмыйбыз, аны «Әйләнә-тирә дөнья» фәне кысасында өйрәнәчәкләр», – дип ачыклык кертте. Кыскасы, дәрестә гаилә, туган як тарихы, Ватан турында фикер алышачаклар. Балаларны музейларга, күргәзмәләргә алып барырга мөмкиннәр.

– Тарих дәресләрен 1 нче сыйныфтан ук укытуның бернинди куркыныч ягы да юк. Һәр башлангыч сыйныф укытучысы тарих дәресен үткәрә ала дип саныйм. Башлангыч сыйныф укытучылары квалификация күтәргәндә, һичшиксез, аның тәртибен булдырырбыз. Без бүген тәрбия, шул исәптән, ватанпәрвәрлек хисен арттыру белән ныграк шөгыльләнергә тиеш. Тарих дәресләрендә генә патриотизм турында сөйләп булмый. Математика, рус теле, туган тел дәресе булсынмы – барысы да шәхес тәрбияләүгә юнәлтелгән, – ди Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин.

Мамадыш районыннан тарих укытучысы Нәсимә Галиева әйтүенчә, тарих дәресен 1 нче сыйныфтан кертсәләр дә, бик әйбәт. Бу вакытта балаларның хәтере тагын да яхшырак була бит.

– Гомумән алганда, укучылар күбрәк җәмгыять белеме белән кызыксына дип уйлыйм. Тарихка килгәндә, 5–7 сыйныф укучыларына әлеге фән кызык. Яңа фән кебек укыйлар. Аннан бу кызыксыну бер мәлгә югалып ала да югары сыйныфларда тагын барлыкка килә. Менә шундый күренеш күзәтелә, – ди Нәсимә Галиева. – Укучылар Бөек Ватан сугышын яхшы белә. «Үлемсез полк»та катнашабыз. Әби-бабайлары тарихын өйрәнәләр, нәсел шәҗәрәләрен төзиләр. Белемнең артыгы булмас.

Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры, тарих фәннәре докторы Радик Салиховның да фикерен белештек.

– 1 нче сыйныфтан ук тарихны өйрәнергә кирәк. Ватанның тарихын өйрәнү аңыбызны ныгыта, ватанпәрвәрлек хисен арттыра. Башлангыч сыйныфларга аны рәсемнәр, җиңел ысуллар, кызыклы хикәя аша өйрәтү отышлы. Бүген мәктәпләрдә Борынгы тарих, Урта гасыр, Россия тарихлары тиешле күләмдә укытыла. Ил тарихы бик бай, ул төрле чорлар цивилизациясен, юнәлешләрне үз эченә ала. Әмма аны тагын да ныграк белсәләр, яхшырак булыр иде, – диде Радик Салихов.

Мәгарифне үстерү институты доценты Марат Лотфуллин да әлеге фикерне хуплый. Аның фикеренчә, гомумән алганда, тарих фәне мәктәптә бик күп укытыла.

– Тарих дәресләре түгел, класстан тыш чаралар, тарихи вакыйгалар турында сөйләү генә бу. Бүгенге шартларда патриотизм тәрбияләүне көчәйтү максаты куелган. Башлангыч сыйныфларда тарихтан мәгълүмат бирүнең зыяны булмас дип уйлыйм. Без барыбыз да – октябрят, пионер булган кешеләр, безгә зыяны булмады. Әгәр кеше мәктәптә үзе белем табарга өйрәнеп үссә, ул барыбер дөреслекне беләчәк, – диде Марат Лотфулллин.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

19 апрель, 2022 ел Казан ш. № 170/1437

2022 елның мартында төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен раслау турында

Тиешле мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен билгеләү буенча Эш төркеменең «2022 елның мартында төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләре турында» 6 апрель, 2022 ел, № 99 карарын тикшергәннән соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2022 елның мартында төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен (Эш төркеменең 6 апрель, 2022 ел, № 99 карарында урын алган) расларга.

2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалының 2022 елның мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

3. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» – «Болгар» радиосы» радиопрограммасы» төбәк радиоканалының 2022 елның мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

4. Бу карарны «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.

5. Бу карарны, бастырып чыгару өчен, «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

6. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары О.В. Сквордяковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

Мәдәният

Шагыйрь белән бер дулкында

Апрель – Тукай ае. Бу айда бөтен җирдә Шагыйрь рухы чагыла, аның шигырь-әсәрләре яңгырый. Казан театр училищесы «Тукай белән бер дулкында» дип исемләнгән театральләштерелгән тамаша тәкъдим итә. Әлеге проект белән без дә танышып кайттык.

Бөек Тукайның тормышы һәм иҗатына багышланган проект турында Казан театр училищесы директоры Руфинә Таҗетдинова белән сөйләштек.

– Без моңа күптән әзерләндек. Спектакльдә училищебыз мөгаллиме, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты Зөлфәт Закиров җитәкчелегендәге 2 нче татар курсы катнаша. Миңа калса, бу – бик кызыклы проект. Ул телебезне, мәдәни кыйммәтләрне саклауга юнәтелгән. Зөлфәт Закиров кулланган режиссер алымнары да гаять кызыклы. Спектакль эстетик һәм рухи яктан гына түгел, мәгърифәти яктан да баета. Студентлар бөек шагыйребезнең тормыш юлын һәм иҗатын сурәтли һәм шул ук вакытта үзләренең осталыгын, сәләтләрен күрсәтә. Алар монда музыка коралларында уйныйлар, җырлыйлар, Тукайның шигырьләрен укыйлар. Спектакль балаларда Тукай, аның шәхесе, шигърияте белән кызыксыну уятыр дип өметләнәм, – ди Казан театр училищесы директоры.

Руфинә Таҗетдинова фикеренчә, спектакль татар телендә аралашучы тамашачыларда гына түгел, ә русча сөйләшә торган кешеләрдә дә татар мәдәниятенә карата кызыксыну уятырга мөмкин.

– Милләтара аралашу, башка милләтләрнең мәдәнияте һәм сәнгате белән кызыксыну үзара хезмәттәшлегебез өчен бик мөһим. Бүген без мультимәдәни дөньяда яшибез. Үзебезнең үзенчәлегебезне саклап калырга гына түгел, мәдәниятебезгә башка милләт вәкилләрен дә җәлеп итәргә тиешбез, – ди ул. – Тамашаны Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе Марат Әхмәтов, парламентның Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов та бик ошаттылар. Алар, студентлар белән сөйләшеп, планнары белән кызыксындылар. Проектны тормышка ашыруда ярдәм иткән өчен мин аларга бик рәхмәтлемен. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та безгә һәрдаим булышып тора. Аңа да бик зур рәхмәт.

Без училищега килгәндә, 2 нче татар курсында репетицияләр бара иде. Сәнгать җитәкчеләре, спектакльне сәхнәгә куючы режиссер Зөлфәт Закиров һәм сценарий авторы, сәхнә теле укытучысы Гаптрәүф Нуриев та шунда иде.

– Бу әсәрне мин студент вакытта Рәүф абый безнең белән дә куйган иде. Еллар узгач, яңа әсәр барлыкка килде. Проект Тукайга, аның шәхесенә һәм ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган. Бу – минем өченче төркемем. Һәр курс белән Тукайга әйләнеп кайтабыз. Яңа буын үсеп килә. Без аларга үзебезнең тарихыбызны җиткерергә тиеш. Спектакль белән татарның гореф-гадәтләрен күрсәтергә тырыштык. Балалар кечкенәдән тарихыбызны белеп, Тукайның иҗатын өйрәнеп үссәләр, милләтебез ныгыячак, – диде Зөлфәт Закиров.

Тамаша биш бүлектән тора. Болар – Габдулла Тукайның бөеклеген раслаган авторларның әсәрләреннән оешкан «Үлемсезлек символы», «Исемдә калганнар», «Тукай Уральскида», «Тукай Казанда» һәм «Чәчәкләр китерегез Тукайга» бүлекләре.

– Тукайның иҗаты колачлап бетерә торган түгел. Ул беркайчан да юкка чыкмаячак. Чөнки татар яшәсен өчен Тукай яшәгән, ул яшәсен өчен без яшибез. Тукай дини темага бик күп язган. Заманында аны никадәр генә атеист, революционер дип күрсәтергә тырышсалар да, ул үзенең намусына бер вакытта да хилафлык китергән кеше булмаган. Без бөтен укучыларыбызны да Тукай аша үткәрәбез, аның иҗатын өйрәнәбез. Әлеге спектакльдә гади авыл мулласының дөньякүләм шигърият йолдызына әверелгән баласы тормышы сурәтләнә. Үзәкләр өзелеп китә торган мизгелләр күп. Балалар бик тырышып, табигый уйныйлар. «Мең кат ишеткәнче, бер тапкыр күрүең яхшы», – диләр. Безнең спектакль дә шул максаттан оештырылды, – ди Гаптрәүф Нуриев.

Ләйсән САФИНА



«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

ЯШӘ, ТУКАЙ ТЕЛЕ!

tatarstan.ru

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Яшь җырчы Сәйдә Мөхәммәтҗанова Президентка Яңа ел алдыннан «Ирония судьбы» фильмын алыштыра алырлык мюзикл төшерү тәкъдимен җиткерде. «Безнең «Әйдә барыйк, кызлар карыйк!» дигән яшьләр мюзиклы төшерү теләге бар. Сценарий буенча, шәһәргә авыл яшьләре, студентлар, эшчеләр килә, алар шәһәр мохитенә җайлашырга, үз урыннарын табарга, гаилә корырга омтыла», – дип аңлатты ул.

– Авыл балалары шәһәргә тиз җайлаша ул, үзебез үк беләбез, моның бер кыенлыгы да юк. Ә менә шәһәрдән авылга кайтып яши башлау кыенрак. Менә шул турыда төшерегез сез. Темасы кызык, бу идеяне хуплыйм, – дип җавап бирде Рөстәм Миңнеханов.

Очрашуда Татар китабы йорты директоры Айдар Шәйхин дә катнашты. Ул шулай ук инглиз язучысы Джоан Роулингның «Гарри Поттер»ын татар теленә тәрҗемә итүче буларак та билгеле. Аның Президентка җиткергән теләге дә яшьләр арасында тәрҗемә эшен популярлаштыру, башка телләрдән татар теленә һәм татар әсәрләрен башка телләргә тәрҗемә итүнең сыйфатын арттыруга бәйле иде. «Яшь язучылар һәм тәрҗемәчеләргә бирелә торган Шәриф Камал премиясен һәм бу юнәлештә эшли торган лабораторияне даими рәвештә һәм сыйфатлы итеп уздыру өчен сезнең «Эшләгез!» дигән сүзегез һәм ярдәмегез кирәк», – диде ул.

Катнашучылар арасында композитор Миләүшә Хәйруллина, «Юлбасма» нәшрияты җитәкчесе Гүзәл Хәсәнова, Тинчурин театры оркестрының баш дирижеры Ильяс Камал, яшь режиссер Айдар Җаббаров, мультиинструменталист Алмаз Әсхәдуллин, «Urban Tatar» яшьләр оешмасы активисты Гүзәл Әхмәтгәрәева да бар иде. Һәркайсының фикерләрен тыңлаганнан соң, Рөстәм Миңнеханов: «Сезне борчыган мәсьәләләр безне дә борчый. Эшли алмастай эш юк. Сез җиткергән, сезне борчыган сораулар безгә дә кагыла. Сезгә шундый позициядә булуыгыз, милләт өчен борчылуыгыз, милләт киләчәге өчен тырышуыгызга рәхмәттән башка сүз юк. Глобальләшү чорында бу эшне алып бару юлларын табарга кирәк. Моңа яшьләрне җәлеп итмәсәк, эшләгән эшебез ни өчен соң? Без киләчәк өчен эшләргә тиеш», – диде.

Өйрәтүче дә, ияртүче дә Тукай

Татар зыялылары, Казан халкы өчен матур традициягә әйләнгән шигырь бәйрәменә – Габдулла Тукай һәйкәле янына – бу юлы мәйдан тутырып килгән иде халык. Быел бит һава торышына да сылтарлык түгел: бәйрәм башланырга төгәл бер минут кала кара болытлар арасыннан, ялтырап, кояш чыкты. Һәйкәл янында, гадәттәгечә, олпат иҗатчылар һәм яшь шагыйрьләр әсәрләрен укыды, җырлар җырланды, Тукай бүләге ияләре макталды, бөек шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салынды.

Яшьләр дә шактый килгән иде. «Идел» яшьләр үзәге директоры Зөлфия Ибләминова сүзләренчә, шигырь бәйрәмендәге мохит һәр татарга якын, кадерле. «Татар филологиясе буенча укыганда ук, Тукай һәйкәле янына бару безнең өчен мөһим бәйрәм, матур бер традиция иде. Ул чакта ук күңелгә сеңеп калган, күрәсең: бирегә килергә ел саен ашкынып торабыз. Мөмкинлек булганда, башка төбәкләрдән килгән татар яшьләренә дә бу чараны күрсәтергә тырышабыз», – диде ул.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин бөек шагыйрьнең Санкт-Петербургтагы һәйкәленә чәчәкләр салды. Ул Төньяк башкаланың Петроград районындагы Тукай скверында урнашкан. «Габдулла Тукай – халкыбызның мәдәнияте символы, кыска, ләкин бик якты гомер кичергән шәхес. Без аның шигырьләрен һәм әйткән васыятьләрен киләчәк буыннарга тапшырабыз», – диде республика парламенты җитәкчесе. Дәүләт Советы Рәисе Санкт-Петербургта эш сәфәрендә. Биредә ул Россия парламентаризмы көненә багышланган чараларда катнаша.

Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев сүзләренчә, безгә әле күп еллар Тукай артыннан барырга кирәк:

– Дөресен генә әйткәндә, мин Тукайга бик озак килдем. Әле шигырьләр яза гына башлаган чагымда, мин Һади Такташ иҗатына бик мөкиббән идем. Ул гадирәк, яшьләрчәрәк тоела иде. Ә Тукайның иҗаты – катлаулы ул. Аның телен аңлау өчен, ислам дине тәгълиматларын, татар халкының тарихын бик яхшы белергә кирәк. Менә шуларны үзләштерә-үзләштерә, мин Тукайны үзем өчен ача башладым. Һәм бүген дә аны ачуымны дәвам итәрәм. Тукай ул – сер дөньясы, – диде ул. – Безгә карагандa бер гасырлап алдан дөньяга килсә дә, узган гасыр кешесе булса да, ул бездән алда бара. Тукай милләтебез һәм телебезнең язмышы, аның киләчәге турында әрнеп, борчылып язган. Әйтерсең ул безнең бүгенге мәгариф системасының хәлен, туган телебезнең язмышын алдан күргән. Шуңа күрә безгә Тукайны да, Тукайдан да өйрәнәсе бар әле.

Тукай туган көнгә багышланган чаралар Камал театры каршындагы мәйданчыкта дәвам итте. Анда да, төгәлрәк әйтсәк, «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә дә яшьлек тавышын ишетергә мөмкин иде.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ЯЗГЫ ИГЕЛЕК АТНАСЫ

КЕМ КҮЧТӘНӘЧ ТАРАТА, КЕМ ӨЙ ЮА

Балтач эшмәкәрләре Асия һәм Радик Закировлар егерме елга якын инде районда яшәүче мөмкинлекләре чикле балалар өчен «Чын күңелдән» хәйрия чарасы үткәрә. Берничә өлештән торган бу чара, зур бәйрәмгә әйләнеп, оттырышсыз лотерея, күптөрле уеннар уздырып, кыскасы, катнашкан һәр бала бүләкле дә, күчтәнәчле дә булырлык итеп оештырыла иде.

Әмма соңгы еллардагы вазгыять үзгәреш кертергә мәҗбүр итте. Быел алар шундый 150дән артык баланы тәм-томнар тулы пакетлар белән сөендерде. Күчтәнәчләрне өйләренә үк илтеп бирделәр. Бу изге эштә аларга халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге белгечләре, авыл җирлекләре хезмәткәрләре ярдәмгә килә.

– Соңгы елларда «Чын күңелдән» хәйрия чарасына балалары Гөлнара һәм Рамил гаиләләре дә теләп кушыла, әти-әниләре башлаган бу изге гамәлнең дәвамлы буласына шик юк, – ди «Наз» халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге җитәкчесе Гөлнара Әхмәдиева. – Быел бу чара язгы игелек атнасына туры килүе белән дә башкаларга үрнәк булды.

«Наз»да эшләүче социаль хезмәткәрләр дә бу көннәрдә әлеге атналыкта катнашкан. Елның-елында бу чорда кызлар үзләре тәрбия кылган өлкәннәрнең өйләрен, тәрәзәләрен юа, буйый, ишегалларын-бакчаларын

чистарта, тәртипли. Үзләренә генә түгел, гаилә әгъзаларына да эш җитәрлек.

– Быел бу атналык дини бәйрәмнәргә әзерлек чорына туры килде. Шуңа күрә христиан динендәге өлкәннәр яшәгән өйләрнең барысын да Пасхага юып-чистартып өлгертү өчен, кызларыбыз бик тырышты. Башка авылларда да инде күпчелек өйләр юылды, тирә-юньнәре чистартылды, бәрәңге утыртучыларның бәрәңгеләре чыгарылды, нигезләре тәртипкә китерелде. Быел кышын да кызларга эш күп булды, карларны вакытында көрәп, язын вакытында канаулар казып та, өлкәннәргә борчылырга урын калдырмадылар, – дип дәвам итә Гөлнара ханым.

Үзәк карамагында ялгыз һәм караучысыз калган 226 кеше бар, аларга 34 хезмәткәр өйгә барып ярдәм күрсәтә. Һәр йортта аларны үз балалары кебек көтеп торалар.

Нөнәгәр авылында өлкәннәргә күп еллар хезмәт күрсәтүче Рамилә Гомәрова турында Әхмәтхан абый Шәфигуллин: «Ярый әле Рамиләбез бар. Үз балаларыбыз булмагач, картлыгыбыз өчен бик кайгырган идек. Мондый рәхәт, бәхетле тормыш насыйп булыр дип уйламадык та. Егерме елга якын инде Рамилә безне үз әти-әниседәй хөрмәтли. Аның тырышлыгы белән чип-чиста өйдә яшим, чип-чиста урын-җирдә йоклыйм... Ул килеп керүгә, өй яктырып китә... Кызганыч, җәмәгатем генә вафат булды», – ди әнә.

Гөлҗиһан апа Фәрзетдинова да еш кына аны коймаклар пешереп көтеп тора икән. Мич коймагын аның «фирменный» ризыгы, диделәр. Авылда берәр бәйрәм булса, заказ биреп тә пешертәләр, болай гына да, тансыклаганнан сораучылар да бар. Ул: «Иртән йокыдан уянуга, Рамиләне көтә башлыйм, – ди. – Бик якын кешемә әйләнде инде ул. Эшенә дә сүз тидерерлек түгел. Бик кешелекле, башкаларны аңлый белә. Аның белән бөтен нәрсәне сөйләшеп була. Акыллы киңәшләрен дә бирә. Безнең бәхетебезгә безгә насыйп булган, дим инде. Ул шулай тырыш булганга, бөтен эшне кешедән алда да эшләп барабыз әле...»

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА.
Балтач

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 260

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+